Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

# КАРАР № XXIII-6

Балык Бистәсе штп. 2022 елның 7 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының югары профессиональ идарәчеләр составын формалаштыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында” 2009 елның 25 февралендәге ПУ-97 номерлы Указын үтәү йөзеннән Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында Нигезләмә (алга таба – резерв турында Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе турында Нигезләмә;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе составы.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә, резерв турындагы Нигезләмә нигезендә, идарә кадрлары резервын формалаштыру буенча эшчәнлекне оештыруны тәэмин итәргә.

3. Үз көчен югалткан дип таныргa:

Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI-6 номерлы карарын;

Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI-7 номерлы карарын;

Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 13 апрелендәге XLIX-2 номерлы карарын;

Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге X-10 номерлы карарын;

Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2019 елның 24 сентябрендәге XLV-9 номерлы карарын.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2022 елның 7
июлендәге XXIII-6 номерлы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибен, җирле үзидарә органнарының идарәче кадрлар резервына конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру кагыйдәләрен һәм шартларын билгели (алга таба - җирле үзидарә органнары).

1.2. Җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турындагы әлеге Нигезләмәдә (алга таба – резерв турындагы нигезләмә) түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Җирле үзидарә органнарының идарәче кадрлар резервы (алга таба - идарәче кадрлар резервы) - резерв турында әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә формалаштырылган гражданнарның тиешле идарәчел вазыйфаларны биләү өчен кирәкле һөнәри мөһим күнекмәләрне үстерү дәрәҗәсенә ия булган затлар төркеме.

Идарәчел вазыйфалар - муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазыйфалары. Әлеге Нигезләмә җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә идарәче кадрлар резервын булдыруны тәртипкә сала, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасыннан гайре. Әлеге вазыйфага билгеләү тәртибе “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы белән регламентлана.

Идарәчел вазыйфага таләпләр – муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренең квалификация таләпләренә туры килә торган йөкләмәләрне (бурычларны) нәтиҗәле үтәү өчен кандидат ия булырга тиешле белемнәр, күнекмәләр җыелмасы.

Профессиональ мөһим күнекмәләр - эш бурычларын нәтиҗәле үтәүне һәм конкрет идарә вазыйфасы таләпләренә җавап бирә торган тәҗрибәнең файдалы үрнәкләре җыелмасы.

## II. Идарәче кадрлар резервына гражданнарны сайлап алу тәртибе

Җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча чаралар үткәрү өчен конкурс комиссиясе оештырыла.

Гражданнарны идарәче кадрлар резервына сайлап алу процедурасы өч этапта гамәлгә ашырыла.

2.1. Конкурсның беренче этабында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында конкурс үткәрү һәм идарәче кадрлар резервына кертелү хокукына документлар кабул итү турында игълан бастырыла.

Идарә кадрлары резервына кертүгә конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында игълан документларны кабул итү датасына кадәр 20 календарь көннән дә соңга калмыйча басылып чыга һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

- муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә муниципаль хезмәт Вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә карата куела торган квалификация таләпләре нигезендә идарәче вазыйфаны биләү өчен резервка кертүгә дәгъва кылучыга куела торган таләпләр;

- резерв турындагы әлеге Нигезләмәнең 2.1.1 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты;

- күрсәтелгән документлар кабул ителә торган вакыт;

- сайлап алу чараларын үткәрү өчен күз алдында тотылган дата, урыны һәм тәртибе;

конкурс турында тулырак мәгълүмат чыганагы турында мәгълүматлар (телефон, факс, электрон почта, муниципаль орган сайтының электрон адресы).

Шулай ук башка мәгълүмати материаллар да урнаштырыла ала.

2.1.1. Идарә кадрлары резервында Россия Федерациясе гражданнары, шулай ук чит ил гражданнары Россия Федерациясе халыкара шартнамәләрендә (алар нигезендә чит ил гражданнары муниципаль хезмәттә булырга хокуклы) катнашучы идарәче кадрлар резервына кертелергә теләк белдергән һәм тиешле сайлап алу конкурсын уңышлы узган чит ил гражданнары булырга мөмкин.

2.1.2. Муниципаль хезмәткәр конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү чорында аның нинди вазыйфа биләвенә карамастан, гомуми нигезләрдә конкурс нигезендә сайлап алуда катнашырга хокуклы.

2.1.3. Конкурс нигезендә сайлап алуны уздырганда кандидатларга Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә хокуклар тигезлеге гарантияләнә.

2.1.4. Россия Федерациясе гражданы яисә чит ил гражданы - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы сайлап алу процедурасында катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхси гариза (резерв турындагы Нигезләмәгә 1 нче номерлы кушымта);

б) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белән Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета (резерв турындагы Нигезләмәгә 2 нче номерлы кушымта) һәм 3 х 4 зурлыктагы фотографияләр;

в) паспортының яисә аны алыштыручы документының күчермәсен;

г) хезмәт кенәгәсенең күчермәсен яисә гражданның билгеләнгән тәртиптә таныкланган хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документларны;

д) һөнәри белем турында, шулай ук, гражданның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, исем бирү турында документларның күчермәләре.

Тиешле документларның төп нөсхәләре сайлап алу чараларына законнарда билгеләнгән тәртиптә үзләре килгәч кандидат тарафыннан шәхсән күрсәтелә.

Граждан тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге өстәмә рәвештә тикшерелергә мөмкин.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Сайлап алуның беренче этабы нәтиҗәләре буенча резерв турындагы нигезләмәнең 2.1 пункты нигезендә документлар тапшырган катнашучылар исемлеге төзелә.

2.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар секторы (алга таба - кадрлар секторы) конкурста сайлап алуның икенче этабында билгеләү өчен кирәкле түбәндәгеләрне бәяләү чаралары үткәрә:

- муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәрен биләү өчен зарур булган белем дәрәҗәсен, төгәлрәк әйткәндә, җирле үзидарә эшчәнлеген оештыру өлкәсендәге кануннарны, хезмәт һәм салым законнарын, идарәнең нәтиҗәле системасын төзү һәм эшләү принципларын һ.б. белүне;

- һөнәри яктан мөһим (идарә итү) күнекмәләрен үстерү дәрәҗәсе, төгәлрәк әйткәндә, ситуацияне анализлау, эшчәнлекне тактик һәм стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру, мәсьәләләрне сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл итү һ.б., шулай ук аларның муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә куела торган квалификация таләпләренә туры килүләре.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә карата куела торган квалификация таләпләре муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә белән расланган.

Бәяләү чаралары компьютер тестын, гамәли биремнәрне, индивидуаль әңгәмәне һәм гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка методларны кулланып үткәрелергә мөмкин.

Икенче этапны узу нәтиҗәләре буенча һәр кандидатка белем бирүнең актуаль дәрәҗәсен, һөнәри мөһим (идарә итү) күнекмәләрен чагылдыра торган нәтиҗә (бәяләмә) ясала.

Төзелгән бәяләмәләр конкурс комиссиясе утырышында карау өчен тапшырыла.

2.3. Конкурста сайлап алуның өченче этабында конкурс комиссиясе утырышы үткәрелә, ул кандидатларны җирле үзидарә органнарының идарәче кадрлар резервына кертү турындагы мәсьәләне карый.

Конкурс комиссиясе каравына идарәче кадрлар резервына кертелү хокукына конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү өчен кандидатларга булган барлык документлар һәм материаллар тапшырыла.

Конкурста сайлап алу беренчел (баштагы) сайлап алу чараларын уңышлы үткән затлар арасыннан гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе үз гамәлләрендә аның утырышына тәкъдим ителгән материаллардан, шулай ук кандидат белән телдән әңгәмә нәтиҗәләреннән файдалана.

Конкурс комиссиясе тәкъдим ителгән кандидатуралар турында фикер алышканнан соң конкурсантны идарәче кадрлар резервына кертү турында карар кабул итә яисә тәкъдим ителә торган кандидатураны кире кага.

Конкурста сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат анда катнашкан кандидатларга конкурс комиссиясе тарафыннан идарәче кадрлар резервына кертүдән баш тарту яисә кертү турында карар кабул ителгән көннән алып бер ай эчендә җиткерелә.

2.4. Идарә кадрлары резервына кертелгән затлар исемлеге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгына җибәрелә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

2.5. Идарәче кадрлар резервына затны кертү күрсәтелгән идарәчел вазыйфага мәҗбүри билгеләнү өчен нигез булып тормый.

2.6. Идарәче кадрлар резервыннан төшереп калдыру нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

-шәхси гариза;

- идарәче кадрлар резервында булу срогы үтү;

- идарә кадрлары резервында булган затның үлеме яисә аны суд карары белән үлгән дип тану;

- муниципаль хезмәткә керүгә каршы килә торган нигезләр барлыкка килү;

- гамәлдәге законнарда каралган башка нигезләр.

Идарәче кадрлар резервыннан төшереп калдыру конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

## III. Җирле үзидарә органнарының идарәче кадрлар резервы исемлеген алып бару тәртибе

3.1. Идарәче кадрлар резервы исемлеген алып бару конфиденциаль характердагы мәгълүматлар булган документларны алып баруга куела торган таләпләр нигезендә кадрлар секторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Гражданның конкурс нигезендә сайлап алу процедураларын кабат узмыйча идарәче кадрлар резервында торуы өч елдан артык була алмый.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
җирле үзидарә органнарында идарәче
кадрлар резервын формалаштыру
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе рәисенә_______________________________________________
_____________________________________________
_______________________________________________,

муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүчедән _______________________________________________
_________________________________________________________
_______________________________________________________

Гариза.

Вазыйфам буенча идарәче кадрлар резервына кертелү хокукына сайлап алу конкурсында катнашу өчен минем кандидатурамны кертүегезне сорыйм________________________________.

Кушымта: документлар исемлеге

имзам _________________________________

Дата “____” ____________, 20___ел

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
җирле үзидарә органнарында идарәче
кадрлар резервын формалаштыру
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
кушымта №2

**ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК**

**Мин**, ______________________________________________________________________,
(ФИАи тулысынча)
____________________________________________________адресы буенча теркәлгән,
_______________________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы документ: _____________, серия: _____ номер: _______________
бирү датасы «_____» __________________, кем тарафыннан бирелгән
_________________________________
_______________________________________________________________________________

"Шәхси мәгълүматлар турында"гы 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсе нигезендә
үземнең эш бирүчемә ___________________________________________
_______________________________________________________________________________
(эш бирүче оешмасының аталышы)

минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә **ризалыгымны бирәм**, аерым алганда, эш бирүчегә тәкъдим ителгән тормышымның фактлары, вакыйгалары һәм шартлары турында мәгълүматлар белән "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсендә каралган гамәлләрне кылуга.

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә аларны эшкәртүгә ризалыгымны биргән минем шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән:

паспорт мәгълүматлары, белем турындагы мәгълүматлар (уку йортының исеме, аны тәмамлау елы, белгечлек), җенес, бүләкләр турындагы мәгълүматлар (шул исәптән бүләкләү датасы), кызыксындыруның башка төрләре булу турындагы мәгълүматлар, эш стажы турындагы мәгълүматларны

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 маддәсе нигезендә мине Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары исеменнән кызыксындыруга тәкъдим итү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары исеменнән кызыксындырылган затлар турында "Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә мәгълүмат саклау максатларында **һәркем (өчен мөмкин) файдалана алырлык дип санауны сорыйм**.

**Мин килешәм**

минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртү 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы "Шәхси мәгълүматлар турында" Федераль закон таләпләренә тулысынча туры китереп башкарылу белән.

**Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгым һәм әлеге килешүдә (ризалыкта) күрсәтелгән максатлар өчен һәркем файдалана ала торган буларак аларны куллану** минем язма рәвештә ясаячак аерым күрсәтмәмә кадәр вакыты чикләнмәгән булып тора.

| | |
|---|---|
| ______________________ | ______________________ |
| (тутыру датасы) | (мөрәҗәгать итүченең имзасы) |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2022 елның 7
июлендәге XXIII-6 номерлы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе турында нигезләмә (алга таба - Конкурс комиссиясе турында Нигезләмә) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын булдыру буенча конкурс комиссиясе эше тәртибе тәгаенләнә (алга таба - җирле үзидарә органнары).

1.2. Җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе (алга таба - Конкурс комиссиясе) коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

1.3. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- җирле үзидарә органнарының идарәче кадрлар резервына кертү өчен кандидатларны конкурста сайлап алуның өченче этабын үткәрү (алга таба - резерв);

- кандидатларны резервка кертү турында карар чыгару.

1.4. Конкурс комиссиясе үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында үз утырышларына бәйсез экспертларны чакырырга хокуклы.

1.5. Комиссия әгъзалары аның эшендә җәмәгать башлангычында катнаша.

## II. Конкурс комиссиясенең эш тәртибе

2.1.Конкурс комиссиясенең эшенә гомуми җитәкчелекне аның хәлиткеч тавыш хокукына ия рәисе гамәлгә ашыра.

2.2. Комиссия рәисе булмаганда яисә аның йөкләмәсе (кушуы) буенча Конкурс комиссиясе рәисе вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

2.3. Конкурс комиссиясе утырышларын әзерләүне, чакыруны һәм уздыруны, беркетмәләр алып баруны һәм карарларны рәсмиләштерүне конкурс комиссиясе сәркатибе тәэмин итә.

2.4.Конкурс комиссиясе утырышлары, әгәр аларда аның составының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы.

2.5. Конкурс комиссиясе утырышы кысаларында резервка кертү өчен беренчел сайлап алу чараларын уңышлы үткән затлар белән әңгәмә үткәрелә.

2.6. Конкурс комиссиясе, фикер алышканнан соң, конкурсантны резервка кертү турында карар кабул итә яисә тәкъдим ителә торган кандидатураны кире кага.

Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны резервка кертү яисә аның кандидатурасын кире кагу өчен нигез булып тора.

Әгәр дә аның өчен утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, карар кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы (ул булмаганда - рәис урынбасарыныкы) хәлиткеч булып тора. Тавыш биргәндә, Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия.

2.7. Конкурс комиссиясе карары билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелә һәм утырышта катнашучы әгъзалар һәм рәис тарафыннан имзалана.

III. Конкурс комиссиясе әгъзаларының җаваплылыгы

3.1. Конкурс комиссиясе әгъзалары кабул ителгән карарның объективлыгы һәм гаделлеге өчен җаваплы.

3.2. Конкурс комиссиясе әгъзалары (һәм Конкурс комиссиясе тарафыннан җәлеп ителгән экспертлар) конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру барышында аларга мәгълүм булган мәгълүматны таратуга хокуклы түгел.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2022 елның 7
июлендәге XXIII-6 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Таҗетдинов Илдар Ршитович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы, комиссия рәисе |
| Җамалиев Рөстәм Рәсимович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| Шәвәлиева Светлана Геннадиевна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының кадрлар секторы мөдире, комиссия сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Шелкова Светлана Александровна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Петрова Эльвина Зәмировна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы |
| Җамалиев Камил Кыямович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Анатыш авыл җирлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Иминова Рәйхана Габделбәровна | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Балык Бистәсе районы буенча җәмәгать ярдәмчесе (килешенү буенча) |
| Шәвәлиев Рафаэль Мәхмүтович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) советы рәисе (килешенү буенча) |
| Керженцева Гүзәлия Фәйзерахмановна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Иҗтимагый совет рәисе, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район халкын эш белән тәэмин итү үзәге” ДБУ директоры (килешенү буенча) |